**Кукмара муниципаль районы**
**Зур Кукмара авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**«28» апрель, 2022 ел** **№ 18**

«2022 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2022 елның 11 апрелендәге 12 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәреш кертү хакында Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:
1. 2022 елның 05 маенда 18 сәгать 00 минутка «2022 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2022 елның 11 апрелендәге 12 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәреш кертү хакындагы мәсьәлә буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- «юлларга вак таш җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру» сүзләрен түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:

- Зур Кукмара авылының Яшьләр урамын асфальтлау, экспертиза ясау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру,
- Зур Кукмара авылы Яшьләр урамында юлга вак таш җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылының Яшьләр урамында 24 нче йорт янында үткәрергә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2022 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара

салымын кертү турында» 2022 елның 11 апрелендәге 12 номерлы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертүгә Сез ризамы:
.
- «юлларга вак таш җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру» сүзләрен түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:

- Зур Кукмара авылының Яшьләр урамын асфальтлау, экспертиза ясау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру,
- Зур Кукмара авылы Яшьләр урамында юлга вак таш җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев